**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**"САВРУШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

№ 3 14 ноябрь 2024 ел

**«Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлегенең Савруш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының Савруш авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә, Аксубай муниципаль районы "Савруш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге җирлеге башлыгы

Карар бирәм:

1. 2024 елның 26 ноябрдә Түбән Савруш Тикшеру комитеты бинасында 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлегенең Савруш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

1. Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлегенең Савруш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан, Украинада махсус операциядә катнашучы мобилизацияләнгәннәрнең һәм контрактчыларның гаиләләреннән тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә;алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә ризамы?

1.Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (Савруш авылы торак пунктында вак таш сатып алу һәм вак таш түшәлгән юлларны ремонтлау, вак ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, юлларны кышкы карап тоту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛДЫМ»

3. Әлеге карарны Савруш авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: http://aksubaevo.tatar.ru Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга. http://pravo.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Савруш авыл җирлеге башлыгы А.Г.Кузьмин